РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА СТАРОГРИШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Ул.Молодежная, д.1, с.Старое Гришкино,
Менделеевский район, Республика
Татарстан, 423642

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ГРИШКИНО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ  БАШЛЫГЫ
Яшьләр ур, 1 йорт,
Иске Гришкино авылы, Менделеевск
районы,
Татарстан Республикасы,423642

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

7 ноябрь 2025 ел　　　　　　　　№ 5

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 18 ноябре 15.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен уздыру урыны итеп Карманково авылы, Урман урамы, 19 йортны билгеләргә.
2. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:
“2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә билгеләргә. I-II төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарын, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын, 18 яшькә кадәр тәрбиядә балалары булган аз керемле күпбалалы гаиләләрне, көндезге бүлектә укучы студентларны, Россия Армиясе сафларына срок хезмәткә чакырылган гражданнарны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?”

1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (агачларны кисү, үләннәр чабу,);
2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту)».

«РИЗА»　　　　　　　　«КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында

http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Иске Гришкино авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы К.И. Алексеев